**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЯСЕ**

| **«КАРАЛДЫ»** | **«КИЛЕШЕНДЕ»** | **«РАСЛАНДЫ»** |
|---|---|---|
| Методик берләшмә житәкчесе<br>____________И.Х.Замалиева<br>МБ утырышы беркетмәсе<br>№1 «25» август 2016 ел | Директор урынбасары<br>________Л.Р.Ягудина<br><br>«27» август 2016 ел | Мәктәп директоры<br>________ [illegible]ллина<br>Педагогик совет беркетмәсе<br>233 нче номерлы боерык<br>белән гамәлгә кертелде.<br>31 нче август 2016 ел |

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Аношина Маргарита Николай кызы
4 «А» сыйныфы өчен татар теле һәм әдәби укудан
эш программасы

Педагогик киңәшмә
Утырышында каралды.
Беркетмә №1
31 август 2016 ел

**2016 – 2017**

## I. Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

Сыйныф: 4 “А”
Укытучы: Аношина М.Н.
Уку планы буенча татар теленнән: 136 сәг.
Атнага: 4 сәг.
Контроль эшләр: 8
Сүзлек диктанты: 2
Күчереп язу: 2
Инша: 1
Сочинение: 1
Кереш контроль тест:1

Дэреслек: Татар теле. Күңелле татар теле. Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен)
Төзүчеләре:Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ә.Гыйниятуллина Татар теле китабы. Ике кисәктән тора. Казан. «Татармультфильм» нәшрияты, 2014 ел

Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында башлангыч гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2016-2017 уку елына укыту планы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016 ел).

**Татар теленә өйрәтүнең предмет нәтиҗәләре.**

1.Сөйләшу

Диалогик сөйләм. 4 нче сыйныфта дәрес вакытының 60-70%ын сөйләшүгә өйрәнү ала. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- сайланган эчтәлек аша әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
- дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

Монологик сөйләм. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеклеген сүрәтләп сөйли белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү.

2.Ишетеп аңлау (аудирование)

Аралашу өчен төп шартларның берсе – әңгәмәдәләрнең бер-берсенең сөйләмен аңлавы. 2 нче сыйныфта ишетеп аңларга өйрәтүнең бурычлары түбәндәгеләр:

- нормаль темп белән әйтелгәннең ишетү аша мәгънәсен аңларга, аңлаган турында фикер йөртергә, аралашуда кулана белергә өйрәтү;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән

ишетү аша аерырга өйрәтү;
- ишетү хәтеренең күләмен үстерү.

3.Уку

Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;
- дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;
- укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;
- кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;
- укыганда сүзлекләр куллана белү.

Дәреслектә уку техникасын үстерүгә ярдәм итә торган рифмовкалар, җырлар, рифмалаштырылган әкиятләр бирелде. Үзләштерү дәрәҗәсенә карап, укытучы аларны арттыра яки киметә ала.

4.Язу

Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбендәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;
- дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;
- бәйрәмнәр белән котлау язу.

Укыту программасы буенча мәгълүмат

Башлангыч сыйныф укучыларының тормышында уен, өй һәм уку хезмәте, гаиләдә һәм дуслар белән аралашу зур урын алып тора. Балалар шулай ук табигать турында сөйләшергә, әкиятләр тыңларга яраталар. Дәреслеккә түбәндәге аралашу темалары кертелде: “Без мәктәпкә барабыз”, “Базарда”, Мин чисталык яратам”, “Кыш”, “Безнең гаилә”, “Яз”, “Туган ягым”, “Кибеттә”, “Җәй”.

Дәреслеккә кызыклы сораулар, чагыштыруны, анализлауны, логик фикерләүне таләп иткән төрле биремнәр кертелде. Мондый биремнәрне балалар кызыксынып эшлиләр, шул ук вакытта өйрәнелгән сөйләм үрнәкләре дә кабатлана.

Һәр дәрестә сөйләм эшчәнлегенең дүрт төре дә катнаша, һәм дәрес максатында күрсәтелгән сөйләм дозасы сөйләм эшчәнлегенең дүрт төре аша да үтеп чыга. Аралашу процессы сөйләшү (диалогик, монологик сөйләм), ишетеп аңлау, уку һәм язу аша оештырыла. Алар арасында төп урынны сөйләшү алып тора.

**Грамматик минимум**

1. Исемнәрнең килеш белән төрләнешен сөйләмдә куллануны камилләштерү.
2. Тартымлы исемнәрнең күплек санда төрләнеше белән таныштыру.
3. Кушма, парлы исемнәрнең мәгънәләрен аңлап, сөйләмдә куллану.
4. Чагыштыру, артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатларның мәгънәләрен аңлап, сөйләмдә куллану.
5. Вакыт рәвешләре (бүген, иртәгә, кичә, иртән) белән таныштыру.
6. Монда, анда рәвешләрен сөйләмдә куллану.
7. Тамыр, кушма, тезмә саннар белән таныштыру.
8. Мин, син зат алмашлыкларының иялек, юнәлеш, урын-вакыт килешләрендә сөйләмдә кулланышы.
9. Кемдер, нәрсәдер алмашлыклары белән таныштыру.
10. Билгесез үткән заман хикәя фигыльне барлыкта 3 затта сөйләмдә куллану.
11. Ашыйсы килә, эчәсе килә формалары белән таныштыру.
12. Кебек бәйлеген сөйләмдә куллану.
13. Кадәр, соң – бәйлекләре белән таныштыру.
14. Ян бәйлек сүзен юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендәкуллану.

15. Уйнарга яратам, уйный башлады – төзелмәләребелән таныштыру.

**Орфоэпик һәм орфографик минимум.**

1. Сүз басымы. Аны дөрес куя белүгә ирешү, рус сүзләре белән чагыштырып күрсәтү. Басымлы иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес уку һәм матур язу күнекмәләре булдыру.
2. Басымның үзенчәлекле очракларын белү.
3. Сингармонизм законының асылын гамәли үзләштерү.
4. Җөмлә ахырында нокта, сорау яки өндәү билгеләрен куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү.

**Педагогик технологияләр**

**Контроль төрләре:**

Өй эшләрен даими тикшереп бару

Укучыларның мөстәкыйл эшләүләрен булдыру һәм аны башкаруны контролдә тоту.

Темалар буенча тест биремнәрен башкару.

Чирек ахырында сыйныфара аттестация биремнәрен үтәү.

**Материаль-техник тәэмин ителү:**

Белем бирү процессын мин коммуникатив методикага таянып, инновацион технология кулланып оештырам (компьютер, проектор, магнитофон)

**Таләп ителгән нәтиҗәләргә ирешү өчен кулланыла торган педагогик технологияләр:**

коммуникатив технологияләр нигезендә укыту принципларын куллану;

телне аралашу аша өйрәнү;

укыту процессын индивидуальләштерү;

телне актив фикерләү нигезендә өйрәнү;

телне функциональ өйрәнү.

V.Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр

Тыңлап аңлау

-Укытучының дәрес, уен ситуацияләре белән бәйле сорауларын, күрсәтмәләрен аңлау;

-тыңлаганда җөмлә, сүз чикләрен билгеләү, интонацияне аеру;

-сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетеп аера белү.

-сүзләрне, җөмләләрне тыңлап тәрҗемә итә белү;

-ишеткән сөйләмнең, җөмләнең эчтәлегенә төшенү.

Диалогик сөйләм:

-Өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;

-программада күрсәтелгән темалар буенча укытучының сорауларына җавап бирү һәм сораулар куя белү;

-дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

Монологик сөйләм

-Җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;

-тәкъдим ителгән план, терәк сүзләр ярдәмендә укылган өзек яисә караган рәсем буенча, өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя төзү;

-укыган хикәяләрнең эчтәлеген сөйли белү;

-үзе, гаиләсе һәм дуслары турында кечкенә информация бирә белү.

Уку

-Татар алфавитындагы хәрефләрне таный белү;

-хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;

-дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;

-тексттагы тыныш билгеләренә карата тиешле пауза һәм интонацияләрне үтәү,өтерләр янындагы сүзләрне тиңдәшлек, эндәшү интонацияләре белән уку;

-укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;

-кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;

-укыганда сүзлекләр 5улана белү.

Язу

-Татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;

-дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;

-бәйрәмнәр белән котлау, чакыру кәгазьләре язу;

-конверт һәм дәфтәр тышына яза белү;

-программада күрсәтелгән темалар буенча, терәк сүзләр кулланып, хикәя язу күнекмәләре формалаштыру.

Уку елы ахырына универсаль уку гамәлләре формалаштыру. УУГ.

Шәхси нәтиҗәләр.

Шәхси универсаль уку гамәлләре:

- “Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, “башкаларга карата түземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү;

- Туган республикага, гаиләгә, туганнарга карата хөрмәт, әти-әнине ярату; үз милләтеңне ярату, татар булуың белән горурлану;

- укуга карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү;

- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләрен һәм геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;Предметара нәтиҗәләр.

Регулятив универсаль уку гамәлләре:

- Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.
- Укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү.
- Укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү.
- Эш сыйфатына бәя бирә белү.
- Эш барышында гади генә эш приборлары белән эш итә белү.( линейка, бетергеч, карандаш, )

Танып белү универсаль уку гамәлләре:

- Дәреслек белән эш итә белү.
- Хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку.
- Этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку.
- Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү.
- Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.
- Укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.
- Предметларны, чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү.
- Укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген сөйли белү.

Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:

- Дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү
- Укытучының, классташларның сорауларына җавап бирү;
- Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү.
- Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.
- Парларда эшли белү

Планлаштырылган нәтиҗәләр

“Татар теле һәм әдәби уку” предметы буенча 4 нче сыйныф программасын үзләштерүнең шәхси нәтиҗәләре:

– татар теленең дәүләт теле буларак ролен аңлау;

– шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру;

– татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге формалаштыру.

--Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау.

Татар теленә өйрәтүнең метапредмет (регулятив, коммуникатив, танып-белү) нәтиҗәләре:

–укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;

–эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;

–дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли белү, алар белән дөрес эш итә белү;

–дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү;

–әңгәмәдәшең белән аралаша белү күнекмәләрен формалаштыру;

–парларда һәм күмәк эшли белү;

–әңгәмәдәшең белән контактны башлый, дәвам итә, тәмамлый белү;

–үрнәк буенча эшли белү;

–аерым темаларга караган сорауларга җавап бирә белү;

–рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү;

–аңлап укый белү;

–укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирү - чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру

## II. Укыту предметының эчтәле

| **Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек** | **Сәг.** |
|---|---|
| Яңа уку елы башлана | 14 |
| Туган як табигате | 24 |
| Хайваннар дөньясында | 11 |
| Кышкы уеннар | 16 |
| Минем дусларым | 18 |
| Дүрт аяклы дусларыбыз | 12 |
| Язгы бәйрәмнәр | 10 |
| Минем туган илем | 10 |
| Чәчәкле җәй, ямьле җәй | 21 |
| Барлыгы | 136 |

**Яңа уку елы башлана.** Яңа уку елы башлана.Уку-язу әсбаплары. Яңа уку елына әзерлек. Минем эш урыным. Без дәрестә. Без контроль эш эшлибез.

**Туган як табигате.** Нәрсә ул табигать? Һава торышы. Дару үләннәре. Кошлар - безнең дусларыбыз. Минем канатлы дустым.

**Хайваннар дөньясында.** Йорт һәм кыргый хайваннар. Кыргый хайваннар турында кыскача мәгълүмат.

**Кышкы уеннар.** Кышкы табигать. Кышкы уеннар. Кар бабай ясау. Яңа ел бәйрәменә барабыз.

**Минем дусларым.** Минем дустым. Дуслар арасындагы мөнәсәбәтләр. Чын дуслык.

**Дүрт аяклы дусларыбыз.** Дүрт аяклы дусларыбызның кыяфәтләре, гадәтләре. Дүрт аяклы дусларыбызга карата мөнәсәбәт.

**Язгы бәйрәмнәр.** Язгы табигать. 8 Март – әниләр бәйрәме. Мин әнигә булышам. Карга боткасы.

**Минем туган илем.** Татарстанның дәүләт символлары. Татарстанда яшәүче милләтләр. Без Казанга барабыз. Татарстан шәһәрләре.

**Чәчәкле җәй, ямьле җәй.** Җәйге табигать. Җәйге ял. Җиләккә бару.

**III. Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру.**

| № | Дәрес темасы | Укыту эшчәнлеге | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| **Тема: Без мәктәпкә барабыз (17 сәг.)** | | | |
| 1 | 3 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау. Яңа уку елы котлы булсын! | Диалог төзү | 2.09 |
| 2 | Яңа уку елы котлы булсын! Текст “Белем бәйрәме” | Парлап эшләү | 3.09 |
| 3 | Яңа уку елы котлы булсын! | Монолог төзү | 5.09 |
| 4 | Уку – язу әсбаплары. | Ситуатив күнегүләр эшләү | 6.09 |
| 5 | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше | Дәреслек белән эшләү | 9.09 |
| 6 | Сузык авазлар, тартык авазлар. **Кереш контроль тест.** | | 10.09 |
| 7 | Хаталар өстендә эш. О, ы, э хәрефләре | Рәсемнәр өстендә эш | 12.09 |
| 8 | 1-10 га кадәр һәм дистә саннары. | Күнегүләр өстендә эш | 13.09 |
| 9 | Текст “ Эш урыны” | Дәреслек өстендә эш | 16.09 |
| 10 | Чөнки, шуңа күрә теркәгечләре. | Диалог төзү | 17.09 |
| 11 | Сәгать ничә? | Күнегүләр эшләү | 19.09 |
| 12 | Текст “Алсу” | Монолог төзү | 20.09 |
| 13 | Күнегүләр өстендә эш | Күнегүләр эшләү | 23.09 |
| 14 | **Контроль эш №1. Тема “Яңа уку елы котлы булсын”** | | 24.09 |
| **Туган як табигате** | | | |
| 15 | Г.Тукай “Елның дүрт фасылы” | Рәсемнәр өстендә эш | 26.09 |
| 16 | Хаталар өстендә эш. Туган як табигате. | Хаталар өстендә эш | 27.09 |
| 17 | Үткән заман хикәя фигыль | Диалог төзү | 30.09 |
| 18 | Гәрәева “Көз һәм балалар җыры” | Парлап эшләү | 1.10 |
| 19 | Көзге табигать | Группаларда эшләү | 3.10 |
| 20 | Текст “Дару үләннәре” | Текст өстендә эш | 4.10 |
| 21 | Кая? Кайда? Кайдан? сораулары | Диалог төзү | 7.10 |
| 22 | Кемне? Нәрсәне? сораулары | Диалог төзү | 8.10 |
| 23 | Кошлар безнең дусларыбыз **Сүзлек диктанты**. | | 10.10 |
| 24 | Хаталар өстендә эш. Бари Рәхмәт “ Кошлар киткәндә” | Хаталар өстендә эш | 11.10 |
| 25 | Кошлар-канатлы дуслар | Рәсем өстендә эш | 14.10 |
| 26 | Канатлы дуслар | Ситуатив күнегүләр | 15.10 |
| 27 | Нәрсә? Нәрсәне? Нәрсәнең? сораулары | Дәреслек өстендә эш | 17.10 |
| 28 | “ Песнәк белән Әнисә”хикәясе. Г.Лотфидан | Текст өстендә эш | 18.10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 29 | Хәзерге һәм үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасы | Диалог төзү | 21.10 |
| 30 | Җ. Тәрҗеманов "Чирик"(1б.) | Текст өстендә эш | 22.10 |
| 31 | Бәйлекләр | Ситуатив күнегүләр | 24.10 |
| 32 | **Контроль эш №2. Тема: Туган як табигате** | | 25.10 |
| 33 | Хаталар өстендә эш. | Хаталар өстендә эш | 28.10 |
| 34 | Җ. Тәрҗеманов "Чирик"(2б.) Инфинитив+ярата төзелмәсе | Җөмләләргә сораулар кую | 29.10 |
| 35 | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше | Күнегүләр эшләү | 7.11 |
| 36 | Күплек сандагы исемнәрнең тартым белән төрләнеше | Ситуатив күнегүләр башкару | 8.11 |
| 37 | Җ. Тәрҗеманов "Чирик"(3б.) | Текст өстендә эш | 11.11 |
| 38 | Күнегүләр эшләү | Ситуатив күнегүләр башкару | 12.11 |
| **Хайваннар дөньясында 11 сәг** | | | |
| 39 | Йорт хайваннары, кыргый хайваннар | Рәсемнәр өстендә эш | 14.11 |
| 40 | Әнәс Кари "Тиен" | Тәрҗемә итү | 15.11 |
| 41 | Билгесез үткән заман хикәя фигыль | Ситуатив күнегүләр башкару | 18.11 |
| 42 | Г.Тукай "Ташбака белән Куян" | Диалог төзү | 19.11 |
| 43 | Сыйфат дәрәҗәләре | Диалог төзү | 21.11 |
| 44 | Әкият " Яшел энәле керпе" | сәхнәләштерү | 22.11 |
| 45 | Кая? Кайда? Кайдан? сораулары | Диалог төзү | 25.11 |
| 46 | "Яшел энәле керпе" әкияте | сәхнәләштерү | 26.11 |
| 47 | Текст "Керпе" | Текст өстендә эш | 28.11 |
| 48 | "Хайваннар дөньясында" темасын кабатлау | Төркемдә эшләү | 29.11 |
| 49 | **Контроль эш №3. Тема: Хайваннар дөньясында** | **Контроль эш** | 2.12 |
| **Тема: Кышкы уеннар(16 сәг.)** | | | |
| 50 | Хаталар өстендә эш. Кыш билгеләре | Хаталар өстендә эш | **3.12** |
| 51 | Сыйфатның артыклык дәрәҗәсе | Диалог төзү | 5.12 |
| 52 | Сорау алмашлыклары | Диалог төзү | 6.12 |
| 53 | Г.Бакир "Кышкы уен" | Текст өстендә эш | 9.12 |
| 54 | Кышкы уеннар. **Күчереп язу.** | Күчереп язу | 10.12 |
| 55 | Билгесез үткән заман хикәя фигыль | Диалог төзү | 12.12 |
| 56 | А.Алиш "Куян кызы" | Ситуатив күнегүләр башкару | 13.12 |
| 57 | Бәйлек сүзләр, кушма сүзләр | Диалог төзү | 16.12 |
| 58 | "Елга буенда" хикәясендәге лексик-грамматик материал | Монолог төзү | 17.12 |
| 59 | Шуа белә, шуа белми структурасы | Диалог төзү | 19.12 |
| 60 | **Контроль эш №4. Тема: Кышкы уеннар** | **Контроль эш** | 20.12 |
| 61 | Хаталар өстендә эш. "Кышкы | Ситуатив күнегүләр | 23.12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | уеннар" темасын кабатлау | башкару | |
| 62 | "Кышкы уеннар" темасын кабатлап биремнәр эшләү | Ситуатив күнегүләр башкару | 24.12 |
| 63 | Биремнәр эшләү | Хаталар өстендә эш. Биремнәр эшләү | 9.01 |
| 64 | Күнегүләр өстендә эш | Күнегүләр өстендә эш | 10.01 |
| 65 | Йомгаклап кабатлау | Йомгаклап кабатлау | 13.01 |
| **Тема: Минем дусларым(18сәг.)** | | | |
| 66. | Исемнәрнең зат-сан белән төрләнеше | Диалог төзү | 14.01 |
| 67. | Исемнәрнең килеш белән төрләнешен сөйләмдә кулланууны камилләштерү | Диалог, монолог төзү | 16.01 |
| 68. | Г. Бәширов "Сылтау" | Текст өстендә эш | 17.01 |
| 69. | Чөнки теркәгече | Диалог төзү | 20.01 |
| 70. | Сүз ясагыч кушымчалар:-чы/че | Монолог төзү | 21.01 |
| 71. | И.Туктар "Алма" | Текст өстендә эш | 23.01 |
| 72. | Вакыт рәвешләре (бүген, иртәгә, кичә, иртән) белән таныштыру | Парларда эшләү | 24.01 |
| 73. | Б.Рәхмәт "Минем дуслар". Чын дуслык. | Монолог төзү | 27.01 |
| 74. | **Сочинение "Минем якын дустым"** | Сочинение | 28.01 |
| 75. | Хаталар өстендә эш. Уйный башлады төзелмәсе | Хаталар өстендә эш | 30.01 |
| 76. | Мин, син зат алмашлыкларының иялек, юнәлеш, урын-вакыт килешләрендә сөйләмдә кулланышы | Диалог төзү | 31.01 |
| 77. | Д.Аппакова "Шыгырдавыклы башмаклар" | Текст өстендә эш | 3.02 |
| 78. | Монда, анда рәвешләрен сөйләмдә куллану | Диалог төзү | 4.02 |
| 79. | Кайдан? кая кадәр? | Парлап эшләү | 6.02 |
| 80. | Билгесезлек алмашлыклары | Монолог төзү | 7.02 |
| 81. | Д.Аппакова "Шыгырдавыклы башмаклар" (дәвамы) | Текст оөстендә эш | 10.02 |
| 82. | Ян бәйлек сүзен юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендә куллану | Ситуатив күнегүләр башкару | 11.02 |
| 83. | **Контроль эш №5. Тема: Минем дусларым.** | Контроль эш | 13.02 |
| **Тема: Дүрт аяклы дусларыбыз(12сәг.** | | | |
| 84. | Минем дүрт аяклы дустым бар | Рәсемнәр өстендә эш | 14.02 |
| 85. | Уйныйсы килә төзелмәсе | Монолог төзү | 17.02 |
| 86. | Г.Тукай "Кызыклы шәкерт" | Текст өстендә эш | 18.02 |
| 87. | Исемнәрдә –сыз/сез аффикслары | Парларда эшләү | 20.02 |
| 88. | Г. Мөхәммәтшин "Ак песи" хикәясе | Текст өстендә эш | 21.02 |
| 89. | Сүз басымы. | Сәнгатьлелек өстендә эш | 24.02 |
| 90. | Сингармонизм законының асылын гамәли үзләштерү | Ситуатив күнегүләр башкару | 25.02 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 91. | Р.Батулла “Чикыл белән Мырый”. Дүрт аяклы дусларыбызның кыяфәте. | Ситуатив күнегүләр башкару | 27.02 |
| 92. | Йөгерә башлый төзелмәсе | Күнегүләр башкару | 28.02 |
| 93. | “Дүртаяклы дусларыбыз” темасын кабатлау | Монолог, диалог төзү | 3.03 |
| 94. | Күнегүләр өстендә эш | Ситуатив күнегүләр төзү | 4.03 |
| 95. | **Контроль эш№6. Тема: “Дүртаяклы дусларыбыз”** | Контроль эш | 6.03 |
| Тема: “Язгы бәйрәмнәр”(10 сәг) | | | |
| 96. | Хаталар өстендә эш. Язгы бәйрәмнәр | Хаталар өстендә эш | 7.03 |
| 97. | Р.Вәлиева “Яз”.<br>Язгы табигать. | Рәсемнәр өстендә эш | 10.03 |
| 98. | Карга боткасы | Проект эше | 11.03 |
| 99. | Парлы сүзләр | Проект эше | 13.03 |
| 100. | **Контроль эш №7. Тема: “Яз килә”** | Контроль эш | 14.03 |
| 101. | Хаталар өстендә эш. М.Газизов “Рәхмәт”. | Хаталар өстендә эш | 17.03 |
| 102. | В. Осеева “Дүрт кыз” | Текст өстендә эш | 18.03 |
| 103. | Табышмаклар илендә | Ситуатив күнегүләр башкару | 1.04 |
| 104. | Ничек әдәпле сорарга? | Диалог төзү | 3.04 |
| 105. | Гади саннар, кушма саннар | Сәнгатьлелек өстендә эш | 4.04 |
| **Тема: Минем туган илем (10 сәг.)** | | | |
| 106. | З.Туфайлова “Туган ил” | Рәсемнәр өстендә эш | 7.04 |
| 107. | Минем Ватаным - Россия | Монолог төзү | 8.04 |
| 108. | Татарстанның дәүләт символлары | Монолог төзү | 10.04 |
| 109. | Татарстанның башкаласы - Казан | Диалог төзү | 11.04 |
| 110. | Г.Тукай “Туган тел” | Төркемләп эшләү | 14.04 |
| 111. | Татарстан шәһәрләре. **Сүзлек диктанты.** | Сүзлек диктанты. | 15.04 |
| 112. | Туган җирем - Алексеевск | Проект эше | 17.04 |
| 113. | “Минем Ватаным” темасын кабатлау дәресе | Проект эше | 18.04 |
| 114. | **Инша “Татарстан – минем туган ягым”** | инша | 21.04 |
| 115. | Хаталар өстендә эш. Күренекле шәхесләр | Хаталар өстендә эш | 22.04 |
| **Тема: “Чәчәкле җәй, ямьле җәй” (21 сәг.)** | | | |
| 116. | Шәүкәт Галиев “Җәйге болында” | **Текст өстендә эш** | 24.04 |
| 117. | Җәйге табигать<br>.Монологик сөйләм. | Монологик сөйләм. | 25.04 |
| 118. | Г.Нәбиуллин “Урман сөйләшә” | **Диалог төзү** | 28.04 |
| 119. | Җәйге урман. Диалогик сөйләм | **Диалог төзү** | 29.04 |
| 120. | **Җиләк – җимешләр. Күчереп язу.** | **Күчереп язу** | 1.05 |
| 121. | Р. Корбан “Җиләктә”<br>Җәйге табигать. | **Монологик сөйләм** | 2.05 |
| 122. | Р. Корбан “Җиләктә” | **Сораулар кую** | 5.05 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 123. | Җөмлә ахырында нокта, сорау яки өндәү билгеләрен куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү | **Ситуатив күнегүләр башкару** | 6.05 |
| 124. | Җәй темасына ситуатив биремнәр | **Ситуатив биремнәр эшләү** | 8.05 |
| 125. | Татар халык ашлары. | **Төркемнәрдә эш** | 9.05 |
| 126. | Ел фасыллары. | **Парлап эшләү** | 12.05 |
| 127. | Татар халык әкияте “Шүрәле” | **сәхнәләштерү** | 13.05 |
| 128. | **Йомгаклау контроль эш** | **Контроль эш** | 15.05 |
| 129. | Хаталар өстендә эш. Күнегүләр өстендә эш | Хаталар өстендә эш. | 16.05 |
| 130. | Күңелле җәй | **Уеннар уйнау** | 19.05 |
| 131. | Татар халык әкияте “Кәҗә белән Бүре” | **сәхнәләштерү** | 20.05 |
| 132. | Җәйге бакча.<br>Диалогик сөйләм | **Диалогик сөйләм** | 22.05 |
| 133. | Җәйге бакча.<br>Монологик сөйләм | **Монолог төзү** | 23.05 |
| 134. | Йомгаклап кабатлау | | |
| 135. | Йомгаклап кабатлау | | |
| 136. | Гомумиләштереп кабатлау | | |

Пронумеровано, прошнуро
и скреплено печатью ___11/один___
татарского языка
и литературы: Аноши